РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ СТАРОАЛЬМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423026, с. Новое Альметьево, ул. Октябрьская, д.19
Тел./факс: 8-(84345) 4-52-46
Email: Salm.Nur@tatar.ru,
ОКПО 0431263, ОГРН 1021605352515,0
ОКАТО 92246872000
ИНН/КПП 1632001515/163201001, ОКТМО 9264772101

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ӘЛМӘТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423026, Иске Әлмәт авылы, Октябрь ур, 19 йорт
Тел./факс: 8-(84345) 4-52-46
Email: Salm.Nur@tatar.ru
ОКПО 0431263, ОГРН 1021605352515,0
ОКАТО 92246872000
ИНН/КПП 1632001515/163201001, ОКТМО 9264772101

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«30» октябрь 2019 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге, Яңа Әлмәт авылы, Мәктәп урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әлмәт авылы төп гомуми белем мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында Мәктәп, Тынычлык, Бакча, Көньяк урамнарыннан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.
2. 2019 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге, Яңа Әлмәт авылы, Мәктәп урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әлмәт авылы

төп гомуми белем мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында Үзәк, Чишмәле, Дуслык урамнарыннан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2019 елның 13 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге, Яңа Әлмәт авылы, Мәктәп урамы, 22 нче йорт адресы буенча урнашкан Яңа Әлмәт авылы төп гомуми белем мәктәбе бинасында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында Болын, Космонавтлар, Шоссе урамнарыннан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча гражданнар җыенын үткәрү өчен бүләргә.

5. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылында халык җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Нурлат муниципаль районы Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты белән тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда Нурлат муниципаль районының Иске Әлмәт авыл җирлеге Яңа Әлмәт авылы территориясендә яшәүче, 1нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1) Су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләргә китерү, Яңа Әлмәт торак пунктының 61 нче 62 нче номерлы скважина янәшәсендәге территориядә объектларны төзекләндерү буенча ремонт эшләре үткәрү.

2) Яңа Әлмәт торак пунктында урам утларын ремонтлау һәм яктырткычлар урнаштыру.

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Иске Әлмәт авыл җирлегенең Яңа Әлмәт авылы мәгълүмат стендларында гражданнар җыены этапларын үткәрү датасына 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Әлмәт авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Хисамов